Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№17 (110)

5 июнь 2014 ел



# Дәверләр күпере - Сабантуй

«Сабантуй – чын мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятенең бетмәс-төкәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлылыкта көч сынашу... Сабантуй турында бөтендөньяга билгеле булыр һәм ул Бөтендөнья мирасы исемлегендә лаеклы урынны алыр дип ышанасы килә», – дигән беренче президентыбыз М.Шәймиев. Балаларны яклау көне уңаеннан, Апас районының шефлыкка алынган белем бирү учреждениеләрендә күңелле һәм шаулы бәйрәм – балалар Сабантуен уздыру матур традициягә әверелде. Балаларны котлау өчен КФУ ректоры, профессор И.Гафуров, уку-укыту эшчәнлеге буенча проректор, профессор Р.Минзарипов, Психология һәм мәгариф институты укытучылары һәм галимнәре, район башлыгы Р.Заһидуллин, һ.б. килгәннәр иде.

## Вакыйгалар эзеннән

30 май көнне ТР Прокуратурасында **«ХЕЗМӘТ КАНУНЫН БЕЛҮЧЕЛӘР»** республика конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Конкурс беренче тапкыр 2011 елда оештырыла. Быелгы конкурста **I УРЫНГА КФУ СТУДЕНТЫ Е.КАРЯГИНА ЛАЕК БУЛДЫ**. Университетыбыз исә иң эшчән вуз исеменә лаек булды.

• • • •

31 майда КФУда **«РОССИЯ-КЫТАЙ ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ: ҖИРЛЕ АСПЕКТ»** темасына багышланган түгәрәк өстәл булды. Анда Кытай халыкара проблемалар институты президенты Цюй Син җитәкчелегендәге Кытай кунаклары, тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты галимнәре, ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм РФ чит илләр министрлыгының Казандагы вәкиллеге хезмәткәрләре катнашты.

• • • •

Мәскәү дәүләт университеты Шувалов корпусының спорт залында М.В.Ломоносов ис. МДУ белән КФУ арасында иптәшләрчә **БАДМИНТОН МАТЧЫ ЯРЫШЫ БУЛДЫ**. Анда ике вузның да студентлары һәм укытучылары катнашты. Әлеге ярыш студентларның бадминтон лигасын ачып җибәрде. Очрашу 6:4 исәбе белән КФУ файдасына тәмамланды. Матч-реванш Казанда, ноябрь аенда үткәреләчәк. Ул уку йортыбызның 210 еллыгына багышланган чаралар кысаларында узачак.

• • • •

2 **ИЮНЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә ректоратның чираттагы утырышы узды. Беренче булып сүз алган Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры **Л.НОГУМАНОВА** 4-5 июнь көннәрендә Алабуга институтында уза торган «Усиление практической направленности педагогического образования на основе организации сетевого взаимодействия вуза и школы» фәнни-гамәли семинар турында сөйләде һәм педагогик юнәлештә эшләүче хезмәттәшләрен әлеге чарада актив катнашырга чакырды. Документ әйләнеше һәм контроль идарәсе җитәкчесе **И.ЛУКАШИНА** контроль йөкләмәләр үтәлеше һәм чаралар планы белән таныштырды. Утырышта шулай ук кабул итү кампаниясе кысаларында А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының презентацион материалын Перспектив үсеш үзәгенең маркетинг бүлеге җитәкчесе **Л.МӨХТӘРОВА** тәкъдир итте. Физика институты, Икътисад һәм финанслар институтында «КФУда электрон белем бирү системасы» пилот проектын тормышка ашыру турында Белем бирү ресурслары үсеше департаменты директоры **Г.ИВШИНА** сөйләде. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** якын киләчәктә узачак федераль дәрәҗәдәге чаралар турында мәгълүмат бирде.

• • • •

4 июнь көнне **«ХӘЗЕРГЕ РОССИЯДӘ ИСЛАМ ЯШӘЕШЕНЕҢ МОДЕЛЬЛӘРЕ: СОВЕТТАН СОҢГЫ ЧОРДА ИДЕЯЛӘР БАЗАРЫ»** исемле түгәрәк өстәл узды. Чарада катнашучылар Россиядәге ислам тематикасының күпкырлылыгына бәйле мәсьәләләр турында фикер алышты. Анда шулай ук илебездә ислам үсешенә йогынты ясый торган факторлар, бу юнәлешләрне тикшергәндә барлыкка килә торган проблемалар турында сөйләштеләр.

• • • •

4-5 июнь көннәрендә Территориаль үсеш һәм идарә институтында **«МАРКЕТИНГ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ»** халыкара конференция булды. Аны икътисади аналитика, маркетинг һәм бизнес өлкәсендә әйдәп баручы белгечләр – **М.ХАЗИН**, **Г.ТРУСОВ** һәм **А.БУЛАТОВ** алып барды.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Белем буразналары

# Иминлек өчен иминият кирәк

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

3-5 июнь көннәрендә КФУда иминиятләштерү буенча «Россиянең базар икътисады шартларында иминиятләштерү системасының социаль роле» XV халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Чараны Казан федераль университеты һәм «Росгосстрах» ААҖ оештырды.

Конференциянең ачылу тантанасы 3 июнь көнне төп бинаның Актлар залында узды. Уникаль фәнни-гамәли конференциягә Россиянең бөтен төбәкләреннән, Армения, Белоруссия, Польша һәм Украинадан килгән катнашучылар саны 180нән артып китте.

Чараның нәкъ менә Казанда үтүе очраклы түгел. Конференция Казан университетының 210 еллык юбилее кысаларында узды. Сәламләү сүзләре белән КФУ ректоры Илшат Гафуров, «Росгосстрах» ААҖ генераль директоры Дмитрий Маркаров, APRIA (Азиатско-Тихоокеанская Ассоциация риска и страхования) президенты, М.В.Ломоносов ис. МДУ проректоры Игорь Котлобовский һәм ТР Иминиятләштерү союзы президенты Рөстәм Сабиров чыгыш ясады. Ректор Илшат Гафуров мондый төр чаралар Казан университеты базасында даими үтәр дип ышана. «Республикадагы финанс-икътисади белем бирүнең үзәге бүгенге көндә - КФУда. Без базар системасы кысаларында эшлибез, бу бик авыр хезмәт. Эш тәкъдим итүчеләрнең үз хезмәткәрләреннән, уку йортында өйрәткәннәрне онытыгыз, дигән заманның артта калуын телибез», – диде ул. Д.Маркаров үз чыгышында конференциядә төп игътибар иминиятләштерү тармагын кадрлар белән тәэмин итүгә, әлеге өлкәдә эшләячәк белгечләрне әзерләү стандартларына һәм фәнни-тикшеренү эшләренең перспектив юнәлешләрен карауга, фикер алышуга биреләчәген әйтте.


Влад Михневский фотолары

Пленар утырыш барышында Россия иминиятләштерү базарының бүгенге хәле, перспектив иминият төрләре, ОСАГО базарының проблемалары һәм башка темаларга кагылган киң мәсьәләләр спектры каралды. Барлыгы 80 докладчы чыгыш ясады. Һәр доклад җыентыкка тупланып бастырылачак.

Пленар утырыштан соң, матбугат конференциясе узды. Монда кунаклар журналистларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

**✦ Белешмә**

«РОСГОССТРАХ» – 92 еллык тарихы һәм зур тәҗрибәсе булган Россиянең эре масштаблы иминиятләштерү компанияләренең берсе, Россия иминиятләштерү базары лидеры (43 млннан артык клиент). «Росгосстрах» ЖЧҖ – РФнең бөтен субъектларында үз эченә 4000 агентлыкны, иминиятләштерү бүлекләрен, сату офисларын, чыгымнарны җайлау бүлекчәләрен алган 83 филиал.

• Сәламәтлек

# Гомумкешелек афәте

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

3 июнь көнне Республиканың медицина профилактикасы үзәге «Наркотикларсыз тормыш» республика акциясе кысаларында «Укый торган яшьләрне наркоманиянең социаль һәм медицина профилактикасы хакында мәгълүматландыру» дип аталган темага лекция уздырды. Чара Казан дәүләт медицина академиясенең психиатрия, наркология һәм психотерапия кафедрасы базасында үтте.

Наркомания проблемасы – аерым бер кешегә генә кагылып калмыйча, бөтен җәмгыятьне борчу-хафага сала торган фаҗига. Ни кызганыч, әмма бу сүзләрдә тамчы гына да арттыру юк. Наркотик матдәләрне беренче тапкыр татып карауга китергән сәбәпләр төрле булырга мөмкин. Тормышта килеп чыккан җитди авырлыклар да, чирләр дә, яңа хис-кичерешләр артыннан куу да, зур һәм текә булып күренергә теләү дә сәбәп булып тора ала. Медицина фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт медицина академиясенең психотерапия һәм наркология кафедрасы мөдире А.М.Карпов та бу хакта сүз йөртте. Презентацияле чыгышында ул наркомания афәте куркынычына каршы торудагы яңа юнәлешләр турында сөйләде. Бу өлкәдә иң мөһим фактор булып, дәүләт ресурсларын һәм кешелек җәмгыяте мөмкинлекләрен берләштерү тора. Профессор сүзләренчә, элек кешеләр күп очракта соматик, ягъни тән авырулары белән авырган булса, хәзерге көндә психик һәм үз-үзеңне тотышта тайпылышлардан интегүчеләр күбрәк икән. Тирә-юнебездәге күпме кеше тәмәкенең, исерткеч эчемлекләрнең, артык күп яисә аз ашауның зарары турында белсә дә, сәламәтлеген какшатуын дәвам итә. Наркомания белән дә шул ук хәл. Әлбәттә, наркоманиягә каршы торуда аерым затларның гына түгел, дәүләтнең дә роле зур. Әмма, ни кызганыч, бүген илебездә бу гасыр афәте белән нәтиҗәле көрәшә торган дәүләт сәясәте юк дәрәҗәсендә. Дөрес, соңгы берничә елда наркотикларны саклаган һәм тараткан өчен җәзалар катгыйлана төште. Тик бу гына аз. А.М.Карпов наркоманиягә каршы торуның цивилизацион-мәгънәви юнәлешенең төп асылын менә нидә күрә: яшьләрне тормыш мәгънәсе турында уйланырга чакыру, аларны белем, иҗат, гармоник үсеш, гадел һәм намуслы, сәламәт тормыш образына өндәү. Ә моның өчен дәүләт һәм кешелек җәмгыяте тарафыннан рухи һәм матди мөмкинлекләр тудырылырга тиеш. Илдәге гомуми мәдәни фон да әһәмияткә ия. Профилактика эшләрен кече яшьтән үк башларга, аларга наркотикларның зарары, аның нинди аянычлы хәлләргә китерә алуы хакында кат-кат сөйләргә кирәк. Чөнки алдан кисәтелгән, физик һәм рухи яктан сәламәт булып үсеп килүче буын гына наркотикларсыз киләчәккә нигез салырга мөмкин.


Влад Михневский фотолары

• Сәнгать

# Космополит рәссам күргәзмәсе

**Ренат МИНИГАЛИЕВ**

30 май көнне КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Манзара» күргәзмәләр залында Булат Гыйльванов иҗатына багышланган «Үткәннәргә кайту» исемле күргәзмә ачылды.

Булат әфәнде – бик талантлы рәссам. 1972 елда Алабуга шәһәрендә туган. 1980-1987 еллар арасында туган шәһәренең И.И.Шишкин исемендәге сәнгать мәктәбендә укыган. 1991 елны Яр Чаллы сәнгать училищесының сәнгать бүлеген тәмамлаган. 1997 елда И.Е.Репин исемендәге Санкт-Петербург дәүләт академик сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтының графика факультетында гыйлем алган. 2001-2005 елларда Россия сәнгать академиясенең иҗат һөнәрханәсендә рәссам-стажер булып эшләгән. 2002 елдан Россия рәссамнары берлеге әгъзасы. 2003 елда аңа «Сказание о Юсуфе» рәсемнәр сериясе өчен Б.Урманче исемендәге ТР дәүләт премиясе бирелә, ә 2007 елда «Алтынчәч» циклы өчен М.Җәлил исемендәге ТР дәүләт премиясе лауреаты була. Аның иҗат җимешләре Россия, Англия,



Төркия, Германия, Япония, АКШ кебек илләрдәге дәүләт коллекцияләрендә һәм шәхси тупланмаларда саклана.

Б.Гыйльванов эшләре тематик һәм стилистик яктан күп төрле. Аларда берберсенә капма-каршы һәм шул ук вакытта бер-берсен тулыландырып тора торган ике юнәлешне анык күрергә мөмкин. Беренчесе – тарихи рәсемнәрне үз эченә алган реалистик рәсем сәнгате. Бу юнәлештә тарихи һәм археологик материал файдаланыла, романтизм стиле кулланыла һәм детальләштерү хас. Үрнәк итеп, «Алтынчәч» картиналары сериясен китерергә була. Икенчесе – Евразия халыклары, борынгы төрки, татар халкы сәнгатьләрен өйрәнеп, оригиналь образлар системасын һәм сурәтләү телен булдыру. Мисал итеп, «Невеста», «Земляника», «Кусочек сахара», «Сказание о Юсуфе» сериясе h.б.

Рәссамның иҗаты белән якыннан танышу өчен, ФһМБИ укытучылары, студентлар һәм кунаклар килгән иде. Күргәзмәне институт директоры Р.Җамалетдинов ачты. Ул Б.Гыйльванов иҗатына зур бәя бирде һәм әлеге күргәзмәнең студентлар теләге буенча оештырылганлыгын әйтте. Рәссамга үзе һәм институт коллективы исеменнән Рәхмәт хаты тапшырды һәм бу очрашуларның алдагы елларда да узачагына ышаныч белдерде. С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе җитәкчесе





З.М.Явгильдина рәссам иҗатының елдан-ел тематик яктан төрлеләнүен һәм рәссамның тамашачыларны яңа әсәрләре белән даими рәвештә сөендереп торуын әйтте. Шулай ук аңа студентларга белем бирү турында да уйланырга киңәш итте.

Сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы мөдире Р.Ф.Сәлахов, шушы ук кафедра доцентлары М.К.Яо, В.Р.Вәлиуллин рәссамның дөнья сәнгатендә талантлы шәхес булуын, милли юнәлештә эшләүче монументалист икәнлеген әйттеләр. Моннан тыш, әсәрләренең көчле хислелеккә корылганлыгы һәм татар халкына гына хас булган моңга бай икәнлеге турында фикер җиткерделәр. Рәсемнәрендә образлар аша талант иясенең сөйкемлелеге чагылуын һәм шул сөйкемле сөяккә бик күп яшьләр тартылуын искәртеп уздылар.

Б.Гыйльванов институт җитәкчелегенә «Манзара» исемле күргәзмә залы булдырганнары һәм иҗатын югары бәяләп, күңелле очрашу үткәргәннәре өчен чиксез рәхмәтен белдерде. Алга таба да үзенең милли юнәлештә һәм бигрәк тә этнофутуризм, ягъни этник мәдәният традицияләренә нигезләнгән хәзерге заман сәнгате стилендә эшләячәген белдерде. Бу фикерен куәтләп: «Мин татар халкының милли мәдәниятен өйрәнә башлагач, үземне космополит итеп тоя башладым. Үз халкың традицияләрен башка халык традицияләре белән чагыштырганда, аларның кардәш булуын, бер чыганактан икәнлекләренә төшенәсең», – диде.

● Юбиляр

# Бөтен яхшы сыйфатларны туплаган шәхес!

Алинә САДЫЙКОВА

Һәрберебез, эштә зур уңышка ирешеп, биек үрләр яулап, шул ук вакытта матур һәм үрнәк гаилә төзеп, бар яктан да килгән кешеләрне беләбез. Без аларга карап сокланабыз, аларга охшарга тырышабыз. Бу сүзләр тулысы белән Лена Кәлимулловна Таҗиевага туры килә. Ул күпләр өчен үрнәк булырлык остаз, ак күңелле һәм эчкерсез кеше. Шушы көннәрдә Лена апа үзенең гомер бәйрәмен, олуг юбилеен каршы ала.



Лена апаның яше байтак булса да, ташып торган энергиясенә, җитезлегенә студентлар да кызыгырлык. Аның характерына хас булган активлык, белемгә һәм яңалыкка омтылыш, креативлык гомер юлын билгеләгән дә.

Әтисе репрессия корбаны булса да, Лена ханым университетка укырга керә. Ул вакытларда андый кешеләр өчен бу бик авыр була. Шулай да, аның максатчанлыгы бу хыялын тормышка ашырырга ярдәм итә. Лена Кәлимулловна мәктәпне бетергәч, авылда китапханәче булып эшли, аннан соң Казан университетына – татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Биредә бер ел белем алганнан соң, аны һәм тагын ике студентны Ленинград университетына Көнчыгыш факультетына укырга җибәрәләр. Анда ул гарәп телен өйрәнә, яхшы укучылар исемлегендә йөри. Биредә өч ел укыгач, Мисырга Каһирә университетына практикага җибәрәләр. «Мин бер сүзсез ризалаштым. Ул вакытларда мондый мөмкинлек турында хыялланган да булмады. Чит илгә артистлар да чыга алмый иделәр әле. Бу бит 1963 ел! Мин өйдәгеләремә Мисырга китәм дип телеграмма җибәрдем. Туганнарым аның кайда икәнен дә белмиләр иде һәм минем чит илгә китүемне аңламаганнар да», – дип көлеп искә ала ул вакытларны Лена апа.

Шулай итеп, мөгаллимә бүгенге көндә дә күпләрнең көченнән килә алмаслык эш башкара – өч югары уку йортында укый. Анда алган белемнәрен туплап, Лена Кәлимулловна 1966 елдан башлап Казан университетының татар теле кафедрасында эшли башлый һәм укучыларын серле гарәп теле дөньясына алып керә. Гарәп теле укытучысы булса да, ул татар, рус, фарсы, француз, алман телләрен дә белә, аларда иркен аралаша.

Лена апада миңа үземә дә бер ел укырга насыйп булды. Аның дәресләрендә курку дигән хис юк иде. Кайбер укытучыларның дәресләренә «икеле» алудан куркып әзерләнсәк, Лена Кәлимулловнаның парларына аеруча хөрмәт йөзеннән һәм аның яхшы мөгамәләсенә рәхмәт йөзеннән әзерләнә идек.

Университетта укыткан 5 дистәгә якын вакыт эчендә мөгаллимә берничә буын тәрбияли, аларга төпле белем бирә!

*«Лена ханым ак төс ярата: ак чәчәкләр ярата, ак костюм кия, ашка барганда, кунак кабул иткәндә, ак яулык бәйләп куя. Бу пакь аклык аңа шулкадәр килешә, безнең өчен аның ак күңеленә башка чәчәкләр, башка төсле яулык килешмәс тә кебек тоела...»*

Флера Сәфиуллина

Шәкертләре – рәссам Нәҗип Нәккаш, тарихчы галим-текстолог Әнвәр Хәйруллин, тамгалар белгече Рөстәм Шәмсутов турында горурланып сөйли. Үз уңышлары, казанышлары белән алар Лена апаларына да бурычлы. «Мәктәпне тәмамлап, әти-әни канатыннан чыгып, университетның зур дәрьясына килеп кергәндә, безгә бар да чит һәм катлаулы булып тоелды. Укуыбызның беренче көннәреннән үк Лена Кәлимулловна безгә ныклы терәк, туры юл күрсәтүче булды һәм әниләргә генә хас җылы мөнәсәбәт күрсәтте. Шул рәвешле беренче тапкыр оешкан безнең гарәп төркемен Лена апа үз канаты астына алды, куенына сыендырды. Төркем эчендә генә түгел, факультет, университет күләмендә туган һәр мәсьәлә буенча да аңа мөрәҗәгать иттек. Ул бер үтенечебезне дә кире какмыйча, үз баласыдай якын күреп, ярдәм итте. Уку дәверендә, кураторыбыз булмаса да, безне әти-әниләребез белән бергә, матур табын әзерләп, бергә җыйды, үзара туганлык мөнәсәбәтләре тудырды. Төркемебез, хәтта факультетыбызның «йолдызы» – Тюрин Романда да татар һәм гарәп теленә мәхәббәт хисе уята, аларның нечкәлекләренә төшендерә алды. Без аңа барысы өчен дә мең рәхмәтле!» – дип искә ала 2012 елгы чыгарылыш, 1175 төркем студенты Әлфия Садыйкова.

Лена Кәлимулловна – хезмәттәшләре арасында да зур ихтирам һәм абруй казанган кеше. Казан университеты профессоры, Ф.Сәфиуллина аның турында: «Бөтен яхшы гадәтләр бер кешегә җыела икән! Лена ханым беркемгә дә беркайчан да зарламыйча, үпкәләмичә, беркемнән дә көнләшмичә, факультетның намусына әверелде», – дип язып калдыра.

Лена апаны юбилее белән тәбрик итәбез һәм балалары, оныклары, шәкертләренең мәхәббәтен һәм ихтирамын тоеп яшәвен телибез!

***Н.И.Лобачевский исемендәге лицейның «Лига» гәҗите материаллары файдаланылды.***



● Чара

# Киләчәк ышанычлы кулларда

**Илдар САФИН,** Саба районы Юлбат урта мәктәбенең тарих укытучысы

Май ахырында Азнакай җирлегендә – «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Азнакай районы: тарих һәм мәдәният проблемалары» дигән темага беренче халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.



Конференция кунакларыннан бер төркем.

Әлеге чарада якын чит илләрдән, Мәскәү, Казан, Уфа югары уку йортларыннан танылган галимнәр, студентлар, тугандаш Кырым республикасы журналистлары, Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарыннан килгән биш йөздән артык делегат катнашты. Килгән кунаклар башта бу төбәкнең горурлыгы булган, республикабызның иң биек нокталарыннан берсе – мәшһүр Чатыр-Тауда экскурсиядә булганнан соң, конференция эшен кереш сүз белән хакимият башлыгы Марсель Шәйдуллин ачты. Аннан соң шушы халыкара чараны оештыруны башлап йөрүчеләрнең берсе – КФУ профессоры Альберт Борһанов бу якларда археологик казу эшләренең барышы, төбәкнең тарихи үткәне турында сөйләде. Соңыннан Мәскәү галиме академик Эдуард Кульпин, академик Мирфатыйх Зәкиев, Молдовадан килгән галимә, Фәннәр Академиясе мәдәни мирас институтының гагаузлар этнологиясе бүлеге хезмәткәре профессор Елена Квилникова һәм башка галимнәр чыгыш ясады. Алга таба конференция үзенең эшен алты секциягә бүленеп дәвам итте, анда йөзгә якын кеше чыгыш ясады.

Район хакимияте, икътисадны алга җибәрү белән беррәттән, тарихны өйрәнү, мәдәниятне үстерүгә дә зур әһәмият бирә икән. Мондый зур форумның Азнакайда үтүе – моның ачык мисалы. Азнакайлылар алга таба да шушы юнәлештә эшне дәвам итәргә, Чатыр-Тауда табигый, тарихи-мәдәни мирас комплексын, шәһәрнең яңа музей бинасын төзергә планлаштыралар. Әйе, шулай булсын, милләт тарихын, үткәнен белгән халыкның киләчәге дә бар.

● Заман таләбе

Шушы көннәрдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Казан университеты, АКШ илчелегенең инглиз теленә өйрәтү офисы һәм Кембридж университеты нәшрияты катнашында «Инглиз телен укытуда инновацияләр: методлар, теорияләр, телгә бәя бирү» исемле халыкара конференция-семинар узды.

# «Инглизчә» фикер алыштык

Ренат МИНИГАЛИЕВ

Без яши торган дөньяның чикләре тарайганнан-тарая бара. Хәзер беренче сәгать эчендә җир шарының теләсә кайсы ноктасына барып җитәргә мөмкин. Техник яктан моның әллә ни кыенлыгы юк. Шулай да, хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләр кала бирә, әйтик, аралашу-аңлашу чарасы буларак, телгә бәйле каршылыклар. Мәдәниятара багланышларның тернәкләнүе, кешелек тарафыннан тупланган интеллектуаль байлыкка карата кызыксыну арту кебек факторлар чит телнең академик дисциплинадан мәдәниятләр аралашуында төп чарага әйләнүенә китерә. Россиянең дөнья күләмендә бара торган сәяси, икътисади, мәдәни, рухи процессларда катнашуы, чит телләрне белүче югары квалификацияле белгечләр әзерләүне таләп итә, ә бу исә, мәгариф системасының мәктәптән башлап, вуздан соңгы баскычларга кадәр телгә өйрәтүнең сыйфатын яңа баштан үзгәртү дигән сүз.

Алда әйтелгән телгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү һәм уртага салып сөйләшү өчен, аерым алганда, инглиз телен укыту өлкәсендә яңа төр укыту методикалары белән таныштыру максатыннан оештырылган конференциягә Новосибирскидан инглиз теленә өйрәтүдә әйдәп баручы белгеч Дженнифер Депто, Белгород дәүләт университетының инглиз теле укытучысы Эрик Ланделл һәм Казаннан Хизер Мело кебек кунаклар килде. Моннан тыш, Казан шәһәре мәктәпләре һәм башка югары уку йортлары укытучылары үз тәҗрибәләре белән уртаклашты. Инглиз теленә өйрәтүче укытучылар мастер-класслар күрсәтте.

• Таныш бул!

# Нәкъ Такташның «Алсу»ы

**Адилә ГЫЙЛАЕВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Сәләтле затларны тасвирлаганда, шагыйрьләр, гадәттә, аларны язгы табигатькә, җирнең кышкы йокыдан уянган мизгеленә тиңли. Ә менә язмабыз герое гүя туганда ук салкын, яңгырлы көз аен җылытырга, безгә теләгәндәй аваз салган бу җиһанга. Иң элек гаилә өчен сөенеч булса, үсә төшкәч, туган авылы, район халкы өчен горурлык булып торуын дәвам итә. Сүзем яшь шагыйрә Алсу Нургатина турында.

Алсу дөньяны шагыйрь-рәссамнарча күреп, танып белергә, һәм шул чынбарлыкны күңеле аша үткәреп, үз дөньясын булдырырга сәләтле кыз бала ул. Нечкә тоемы, образлы күзаллавы, тел байлыгы булмаса, билгеле, моңа ирешү мөмкин түгел. Яшь каләм ияләренең республикакүләм төрле әдәби ярышларында җиңүләр, шул исәптән «Гран-при»лар яулап, Казан университетына имтиханнарсыз гына үтә алды. Димәк, максатчанлык, тырышлык җитәрлек бу кызда! Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Алсу яшь каләм тибрәтүчеләрне үзенә җыя торган «Иделем акчарлагы» конкурсында поэзия номинациясендә 1нче урынга, прозада - кызыксындыру бүләгенә лаек булды. Хәзерге көндә ул КФУның гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының 3 курсын тәмамлый.

**- Алсу, шагыйрьлек сәләте кешегә тумыштан ук бирелергә тиеш, өйрәнеп кенә шигырь язу мөмкин түгелдер. Синеңчә, кем ул шагыйрь?**

- Шагыйрь кеше һәрнәрсәне күңеленә үтә дә ихласлык белән кабул итә. Мәсәлән, төнен юлдагы күлләвекләрдә гади кеше пычрак су күрсә, ул йолдызлар күрә, айны күзәтә. Әгәр дә шундый ихлас тоемлау булмаса, өйрәнеп кенә шагыйрь булып булмыйдыр ул, минемчә.

**- Шигырь язганда, күбрәк нинди темаларга өстенлек бирәсең?**

- Яшьлек чоры, әлбәттә, мәхәббәткә табына. Шуңа да күп шигырьләрем иң ихлас хисләр белән сугарылган. Күбесенчә, үз күңелемә якын темаларга язарга яратам. Андый чакта шигырь тирән мәгънәле һәм үтемле була.

**- «Безнең гәҗит» газетасында басылып чыккан «Сынаулар» повестен күпләр үз итте. Хикәя, повесть геройларын тормыштан аласыңмы яки уйлап чыгарылган персонажлармы?**

- Проза - яраткан жанрларымның берсе. Шигъри юлларга сыймаган хисләрне хикәяләргә күчерә алуыма шатланам. «Сынаулар»да күп геройлар үз тормышымнан, күргән-белгән кешеләр. Шулай ук уйлап чыгарылган персонажлар да бар.

**- Хәзерге заманда шагыйрь булу җиңелме**?

- Әгәр кеше үз эшенең остасы булса, бер генә һөнәр дә җиңел бирелми. Ләкин эшләгән эшең сиңа канәгатьлек хисе китерә икән, димәк, син ул йөкне теләп һәм яратып күтәрәсең. Шагыйрьлекне һөнәр итеп сайлаган кеше хәзерге көндә үз тамагын үзе туйдыра алмый.

**- Алсу, синең иҗатың белән кайда танышып була?**

- Вконтакте сәхифәсендә төркемем бар, шунда иҗатым белән танышып була. Шулай ук вакытлы матбугатта еш басылам.

**- Шагыйрьне шагыйрь иткән сәбәпләрне санап китсәңче?**

- Тукай әйтмешли, «Илһамчысы булмаса, шагыйрь, шагыйрь була алмый инде ул». Килешәм. Бу - Ходайдан килгән хисси тоемлау. Талант, дар. Аны акчага сатып алып булмый, бары вакытында күреп алып үстерергә генә кирәк.

**- Шигырьләреңә көй язучылар юкмы?**

- Көй язучылар бар, Чаллы шәһәрендә яшәүче апам бер шигыремә көй язды.

**- Хөрмәт иткән, яратып укыган шагыйрең бармы?**

- Яраткан шагыйрем - Һади Такташ. Кечкенәдән аның иҗатына гашыйк кеше мин.

**- Бүген әдәбиятыбызга яшьләр килә. Аларга карашың нинди?**

- Тырышрак булырга кирәк. Һәр заманның үз Тукае булырга тиеш...

**- Уңышлар сиңа, Алсу! Киләчәктә дә иҗат баскычының югары үрләрен яуларга язсын сиңа, дустым! Каләмең һәрвакыт үткен булсын!**

## *Ибраема*

*Урамга күз салам. Төнге ун.*
*Авылым, син шундый үзгәргән!*
*Тар тыкрыклар буйлап*
*шыпыртын,*
*Яшьләр йөри безнең эзләрдән.*

*Хыялны чын иткән бер тарих.*
*Күңелле авылда җәйге төн.*
*Старт биреп, «матай»лар кузгала*
*Тарала... Тарала тик төтен.*

*Авылым, син шундый илаһи,*
*Төннәрең дә якты бит синең.*
*Киткәндә күңелем чык булып*
*Пәрәвез җебенә киселде...*

*Бу төндә күңелем күгенә*
*Таңдагы томаның тарала.*
*Ятим итмә мине син, кичер*
*Мәңгелек сагыштан арала...*

*Сагынып кайттым бит...*
*Нәкъ бүген*
*Кадереңне аңлар төн җитте.*
*Җанланган урамны күзәтәм,*
*Бер-ике минуттан үнике...*

• Хак-нахак

# Белем алу ничә сум тора?

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

«Акыл белән алтын табыла, алтын белән акыл табылмый», дигән мәкальне ишеткәнегез бардыр. Тик, кызганыч, хәзерге көндә бу әйтем актуаль түгел, чөнки һәр нәрсәне сатып ала торган чорда яшибез. Шул исәптән, акылны да. Хәзер, яхшы белем алыр өчен, шактый күп акча түгәргә кирәк бит.

## Чынга ашмаган хыял

Университетның бишенче курсында уку миңа уку йортларында ришвәтчелек проблемасы турында фикер йөртергә хокук бирә дип уйлыйм. Чын күңелдән әйтә алам, үземнең беркайчан да ришвәт биргәнем юк, әмма белемне сатып алган кешеләр белән таныш. Ришвәтнең алар тормышына тискәре тәэсир ясаганын да беләм. Танышым Данил ике ел элек популяр уку йортын тәмамлый. Гомер буе юрист булырга хыяллана. Мәктәптә укыганда, ул киләчәктә кирәк булачак фәннәр буенча репетиторларга йөри. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. Хыялын тормышка ашырыр өчен, көченнән килгәннең барысын да эшли. Тик теләгән белгечлеге буенча белем ала алмый, акчасы җитми. Шуңа күрә икенче елны башка бүлеккә укырга керә. Шуңа күрәдер, аның билгеләре «өчлеләр»гә төшеп бетә, белем алу теләге тәмам сүнә. «Бүген мин яхшы яшим. Хезмәт хакым да әйбәт, тормыш иптәшем дә бар. Тик кайбер вакытта уйланып калам: теләгем буенча укырга керсәм, тормышым бөтенләй икенче булыр иде бит! Балаларымның хыяллары тормышка ашсын өчен, алар мәктәпкә укырга кергәч үк акча җыя башлаячакмын», – ди Данил.

Данил теләгән уку йортына ришвәт бирмичә керә алмады, ә бит күп кенә студентлар төрле имтиханнарны, зачетларны бирер өчен, китап укып ятмый, ә укытучыларга акча «бүләк итә». Үткәргән сораштыру нәтиҗәсе шуны күрсәтте: 50 студентның 13е тормышта бер тапкыр булса да ришвәт биреп караган. Хокук бозганнарның яртысы моны физкультура дәресенә йөрмәс өчен эшләгән. Рамил әнә шундыйлардан, әлеге дәрескә ул йөрергә иренә. Ә ришвәт күләме әллә ни зур түгел, аңа өстәп, укытучылар белән семестр башыннан ук сөйләшеп, дәрескә бер тапкыр да килмәскә була, ди ул.



Сораштыруда катнашкан студентларның өчесе ришвәтне укытучылар таләп иткәч биргән. Сүзләренә ышансаң, алар фәнне бик яхшы өйрәнгән, әмма укытучы махсус батырган, шуңа күрә студентларга ришвәт бирүдән башка бернинди юл калмаган.

## Сессия – уңыш чоры

Ришвәтчелек проблемасы, кызганычка каршы, булды, бар һәм булачак. Бердәм дәүләт имтиханнарын гамәлгә керткән вакытта түрәләр: «Ришвәтчелек бүтән булмаячак!» – дип әйткәннәр иде. Ә ул, киресенчә, тагын да җәелеп китте: акча биреп, яхшы баллар җыю ысулы мәктәпләргә күчте.

Ришвәт алу укуга кергәч тә дәвам итә. Дөрес, имтиханнарны үз белемнәре белән бирүче студентлар бик күп. Тик аларга да кайчакта акча чыгарып салырга туры килә.

Акчаның иң «уйнаган» вакыты– сессия. «Трай» тибеп йөрүче һәм семестр буе тырышып укучы студентлар бер «казан»да кайнып торган вакыт бу. Чөнки аларның максат бер – сессияне ябу. Бер танышым, мәсәлән, укырга йөрми диярлек. «Мине әти-әни укырга кертте. Югары белем алырга теләмәгән идем», – ди егет. Шуңа күрә уку вакытында ул эшли, ә сессия килеп җиткәч, ничек булса да аны ябарга тырыша. Аның фикеренчә, күп укытучыларны сатып алып була. Кемгәдер акча кирәк, кемгәдер – аерым бүләкләр. «Аларны аңлап була, шулхәтле нервы бетереп, кечкенә хезмәт хакы ал әле син! Бөтен кешенең дә яхшы яшисе килә», – ди ул.

## Сатып алу очсызрак

Хәзер курс эшләрен, рефератларны сатып алып булган кебек дипломны да алып була бит. Бу да үзенә күрә бер ришвәт. Ниндиен генә эшләмиләр аның?! Акчаң гына булсын. Кайберәүләр өчен диплом сатып алу биш ел буе вузда укуга караганда да арзанракка төшә. Сүз дә юк, белемне сатып алып була. Тик ул «белем» алга таба башкаларга зыян китермәсен иде...

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.